**СОВЕТ**
**НОВОШЕШМИНСКОГО**
**МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**
**РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул. Советская, д.80,
с. Новошешминск,423190

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ЯҢА ЧИШМӘ**
**МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**СОВЕТЫ**
Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы, 423190

тел.: (8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22, chishma@tatar.ru

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советы
КАРАРЫ

2022 елның «7» июленнән № 24-186

«2022 елда Яңа Чишмә муниципаль районында балаларның һәм яшүсмерләрнең ялын, сәламәтләндерүен һәм мәшгульлеген оештыру турында»

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге башлыгы М. А. Магомедованың «2022 елда Яңа Чишмә муниципаль районында балаларның һәм яшүсмерләрнең ялын, сәламәтләндерүен һәм мәшгульлеген оештыру турында»гы мәгълүматын тыңлаганнан соң, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советы

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге башлыгы М. А. Магомедованың «2022 елда Яңа Чишмә муниципаль районында балаларның һәм яшүсмерләрнең ялын, сәламәтләндерүен һәм мәшгульлеген оештыру турында»гы мәгълүматын игътибарга алырга.

2. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлегенә:

- балалар һәм яшүсмерләрнең ял итү һәм сәламәтләндерү системасын саклау, шулай ук төрле милек формаларындагы сәламәтләндерү учреждениеләрен үстерү буенча конкрет чаралар күрергә;

- балигъ булмаганнарның күзәтүчесезлеген һәм хокук бозуларын профилактикалау буенча өстәмә чаралар күрергә;

- спорт чараларын уздыру өчен спорт мәйданчыкларын максималь йөкләнеш белән кулланырга.

3. «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф бүлеге» муниципаль учреждениесенә:

- «Факел» ял һәм сәламәтләндерү учреждениесе һәм мәктәп яны лагерьларында төп эш урыны буенча хезмәт хакын саклап калып, педагогик кадрлар һәм хезмәт күрсәтүче персонал белән тәэмин итәргә;

– ятим балаларның, сәләтле балаларның һәм гомуми белем бирү мәктәпләре укучыларының сәламәтләндерү лагерьларында, мәктәп яны лагерьларында көндезге ялларын һәм сәламәтләндерүләрен оештыруны тәэмин итәргә;

- җәйге каникуллар чорында барлык өстәмә белем бирү учреждениеләренең эшләвен тәэмин итәргә.

4. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының мәдәният бүлегенә:

- мәктәп яны лагерьларында ял итүче балалар өчен музыкаль-массакүләм чаралар оештырырга;

- мәктәп яны лагерьларында күчмә китапханәләр һәм кино күрсәтү эшен оештырырга.

5. «Яңа Чишмә РҮХ» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенә тәкъдим итәргә:

- «Факел» ял һәм сәламәтләндерү учреждениесен медицина кадрлары белән контракт нигезендә комплектлау;

- балаларны сәламәтләндерү учреждениеләренә эшкә җибәрелә торган персоналга медицина тикшерүләре һәм лагерь персоналына гигиеник укулар үткәрүне оештырырга;

- балаларны сәламәтләндерү учреждениеләренә эшкә җибәрелә торган персоналны укудан һәм каникулдан буш вакытта эшкә урнаштырганда, балигъ булмаганнарга медицина тикшерүләрен оештыруны тәэмин итәргә;

- балаларны сәламәтләндерү учреждениеләренә эшкә җибәрелә торган персоналны сезонлы карау кысаларында түләүсез флюорография тикшерүен тәэмин итәргә;

- кирәк булган очракта балалар сәламәтләндерү учреждениеләрен медицина җиһазлары белән тәэмин итәргә;

6. «Яңа Чишмә районы халыкны эш белән тәэмин итү үзәге» дәүләт казна учреждениесенә балигъ булмаган гражданнарны (шул исәптән күп балалы гаилә балалары, балигъ булмаганнар эшләре буенча комиссиядә торучы СОП балалары) буш вакытларында, Татарстан Республикасы бюджеты акчаларыннан матди ярдәм түләп, вакытлыча эш белән тәэмин итүне оештырырга тәкъдим итәргә.

7. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Финанс-бюджет палатасына:

- чыгымнар сметасы буенча «Факел» стационар лагерен һәм көндезге лагерьларны тотуга акча бүлеп бирүне тәэмин итәргә;

- балалар һәм яшьләрнең ялын, сәламәтләндерүен һәм мәшгульлеген оештыруга бүлеп бирелгән акчаларның максатчан кулланылышын контрольдә тотуны тәэмин итәргә;

- җәйге каникуллар вакытында оештырылган балалар мәйданчыкларында балаларның ялын оештыру буенча эшләрне финанслауны күздә тотарга.

8. Әлеге карарны Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында http://novosheshminsk.tatarstan.ru/ бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

9. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының социаль, агросәнәгать һәм азык-төлек сәясәте буенча даими депутат комиссиясенә йөкләргә.

Яңа Чишмә муниципаль районы Башлыгы В. М. Козлов